# – Й –

***Йа*** – Ымлык (русча – *междометие*). Соклану, гаҗәпләнү, ялвару, сукрану кебек хисләрне белдерә һәм шулай ук риторик сорау белән мөрәҗәгать иткәндә кулланыла. // *Йа Алла, миңа бу эшне дә отарга ярдәм ит!* Г. Тукай. *«Йа Хода, хифыз әйлә падишаһы!»* – «Йа Хода, падишаһны саклый күр!» (Патша Россиясенең дәүләт гимны сүзләре: *«Боже, царя храни!»* – 1917 елга кадәрге иске тәрҗемәдән.)

***Йа сабаха-һу!*** *г.* – Нинди дә булса куркыныч янаганда, гарәпләрдә халыкны җыю өчен кычкырып әйтелә торган сүзләр. Монда *һу* «Аллаһу» мәгънәсендә.

***Йабагай*** – Ярлы. Асылда, монгол теленнән кергән сүз дип карала. Монголча *йабугай* – атсыз, җәяүле, ягъни юксыл (кеше). Бүгенге татар телендә парлы *ярлы-ябагай* сүзендә күзәтелә.

***Йабакулак*** *бор.төр.* – Ябалак (кечкенә каурый «колак»лы кош, русча – *сова ушастая*). *Йабакулак* сүзе Мәхмүд Кашгарый сүзлегенә (XI гасыр) теркәлгән. Охшаш сүз каракалпак, хакас, Себер татарлары телендә дә бар. Р. Әхмәтьянов бу сүзне «ябай [кыргый] ат колагы шикелле колаклы» мәгънәсендә дип аңлата һәм: «Бу кошларны «йаба колак» дип атау, ихтимал, «Табу» йоласыннан килеп чыккандыр», – дип өсти. Ә мәче башлы ябалакның яки байгышның русчасы – *филин*, аның да каурый «колак»лары бар. Мәче башлы ябалак гәүдәгә зур – озынлыгы 46–72 сантиметргa җитә. «Мәргәннәр җыруы»нда «байгыш» мәгънәсендә очрый торган *өге* атамасы аваз охшатымы буенча бирелгән. Диалектларда мәче башлы ябалакны «бабалаш», «ихахай җабалак» дип тә йөртәләр, ә бер төре «оңгыт» дип атала. *Кызан,* яки *кыза* – тычкан тота торган ябалак.

Борынгы татар телендә *ябалак* сүзенең икенче мәгънәсе – «юка, ялпак». «Ябалак кар» дигәндә, сүзнең шушы мәгънәсе күздә тотыла.

***Йабандә-җуйәндә әст*** *г.* – Эзләгән табар. Әйтем.

***Йабгу*** *бор.төр.* – Көнбатыш төркиләрдә баш хаким (хан) титулы. Борынгы төрки каһанлыкларда каһан белән бергәләп идарә итүче, яки каһан билгеләгән тәхет варисы. Татарча чыганакларда бу сүзнең язылышы артык чуар – чыганакларда *йафгу, йавгу, җабгу* һәм *ябгу* вариантлары теркәлгән. // *Тай Билгә-тутукуг йабгу атады* – ул Тай Билгә-Тутукка ябгу титулы бирде. «Древнетюркский словарь»дан.

***Йавук*** *бор.төрк.* – **1.** Якын (кеше). // *Кемне йавук иткән булсаң, шуны ерак озатырсың.* Борынгы сүз. **2.** Якын (ара). // *Үтте егетлек куәте, / Йитте карыйлык нәүбәте, / Килде йавук мәрге ахры, / Мин егъламай кем егъласын?* Кәрим Хөбби.

Тагын кара: *Евык.*

***Йаг*** *бор.* – Май. Мәс., хәзерге *ягу* (сылау) сүзендә сакланган («май ягу»). «Күз явын алырлык» дигәндә, «күз мае» аңлашыла. «Авызыңа бал да җау» дигән сүз дә бар. // *Кара йаг* (карамай) – борынгы төрки телдә нефть. *Көнҗет йагы* – көнҗет мае. *Саг йаг* – сыер мае, акмай, атланмай. (Борынгы төркичәдән; монда *саг* – *саг-* (саву) фигыленнән.)

***Йаган/йаңан*** *бор. төр.* – Фил. Элек бу сүз кеше исеме булып та йөргән, титулны да белдергән. *Йаган* исеме Казан шәһәренең XVI–XVII гасырларга караган сан алу кенәгәләрендә очрый.

Тагын кара: *Фил.*

***Йагкуб пәйгамбәр*** – Коръәни шәхес, Ибраһим кауменнән изге кеше, Йосыф пәйгамбәрнең әтисе. Библиядә – *Иаков.* Коръәндә Йагкуб исеме аның улы Йосыф турындагы сүрәдә еш телгә алына (12:68, 93–94). Хронологик яктан соңгырак сүрәләрдән аның *Исхак* улы булганлыгы күренә (2:130, 134), ләкин иртәрәк иңгән сүрәләрдә ул *Ибраһим* улы һәм Исхакның туганы дип күрсәтелгән (6:84, 19:50, 21:72, 19:26). Коръәндә аның икенче исеме – *Исраил* (Алла колы). Коръәннең «Йосыф» сүрәсендә (12:4,6) Йосыф атасы Йагкубка төшендә унбер йолдыз һәм кояш белән айның үзенә сәҗдә кылулары турында сөйли. Йагкуб аның төшен Раббың сине Исхак белән Ибраһим кебек пәйгамбәр итеп сайлыйдыр вә сиңа төш юрауны өйрәтәдер дип аңлата. «Йосыф» сүрәсенең ахырында ул угылларына Мисырга бер капкадан кермәскә боера. Йосыфның күлмәген аның йөзенә каплагач, Йагкубның күзләре кабат күрә башлый (12:67 – 68, 93–96). «Гимран» сүрәсенең 93 нче аятендә: «Йагкуб балаларына барча ризык хәләл булып, мәгәр Тәүрат иңмәс борын үзләре хәрам кылган нәрсәләр хәләл түгел иде», – диелгән («Ногмани тәфсире» буенча). Йагкуб пәйгамбәр: «Сырхау чагымда сәламәтләнсәм, дөя итен вә сөтен үземә хәрам кылырмын», – дип нәзер әйткән була, аңа карап балалары да бу ризыкларны үзләренә хәрам кылалар («Ногмани тәфсире», 3:93), ләкин риваятьләрдә Исраилнең ботлары авырткан һәм ул бот сеңерләрен ашауны тыйган дип сөй-

ләнә (мондый тыю турында «Яшәеш» китабында сүз бара).

Коръәннән соңгы риваятьләргә караганда, *Йагкуб* – игезәк балаларның берсе, ә икенчесенең исеме *Исав* булган. Риваятьләрдә һәм тәфсирләрдә Йагкубның ана карынында чакта ук Исав белән көрәшкәнлеге турында сөйләнә. Йагкуб беренче булып дөньяга килергә тиеш булса да, Исав аны көч белән төрткәләп читкә этәргән һәм, шул рәвешле, өлкән угыл булып туган, имеш. Бүгенге фән дә игезәкләр арасында ана карынында чакта ук мәгълүм мөнәсәбәтләр барлыкка килүен кире какмый.

Татарча чыганакларда *Йагъкуб* һәм *Ягъкуб* язылышлары очрый.

Тагын кара: *Якуб/Якуп.*

***Йад идеңез*** *иск.* – Искә алыгыз; ятлагыз. Кара: *Яд.*

***Йада*** *ф.* – Фарси *җаду* сүзеннән булырга кирәк. Борынгы төркиләрдә карлы-яңгырлы көчле давыл кубару өчен таш ярдәмендә эшләнә торган ырым (сихер) йоласы. Себер татарларында тылсымлы ташның үзен «йада» дип атыйлар. // *Йадачы* – тылсымчы, сихерче.

Тагын кара: *Җаду.*

***Йадыган*** – Себер татарларында гөслә, ятма арфа.

***Йази*** *бор.* – Дала. Диалектта *язы* формасында сакланган (зур кыр, дала). «Язылу (җәелү)» мәгънәсенә бәйле дип карала. // *Язи-ябан, язи япан* – (җәелеп/җәйрәп яткан) кыр-далалар.

***Йазид*** – Кара: *Йәзид.*

Русча чыганакларда: *Язид I.*

***Йазма*** – **1.** Гөбе әйрәне. Май язганнан соң кала торган сөтчел сыекча. **2.** Катык әйрәненә кыяр, суган турап әзерләнә торган сыек ашамлык. Руслардагы *окрошка*ны хәтерләтә.

***Йай*** – Гарәп әлифбасында егерме сигезенче хәреф. Әбҗәд хисабында 10 санын белдерә. // *Әгәр Йә булса, дошманнарың дуска әйләнер* (Коръән белән фал ачуда).

***Йакатт*** *г.* – Яка (кием якасы). Ләкин Р. Әхмәтьянов *яка* сүзенең гомумтөрки сүз булуын дәлилләп, аның чик, кырый, чит, яр (буе) һ. б. мәгънәләрен күрсәтә һәм йоны тышка калдырып тегелгән тун – *доха* да шул тамырдан дигән фикерне әйтә. Бу очракта гарәпчә һәм төркичә сүзләр үзара керешеп, берләшеп киткәннәр булса кирәк.

Тагын кара: *Яка.*

***Йалңук/йалыңук*** *бор.төрк.* – Мәхмүд Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрк» сүзлегендә (XI гасыр) теркәлгән сүз, «кеше» мәгънәсендә йөргән, төркиләр Адәм галәйһиссәламне шулай атаганнар. Борынгы төркичәдәге *йалың* сүзенең «шәрә», «ялангач» мәгънәсендә булуына игътибар итик (*йалың эр* – ялангач ир; *йалың келдим йерди, йалың киргү йеркә* – ялангач килдем һәм җиргә ялангач керергә тиешмен. Бу мисаллар «*Котадгу белек*»тән). // *Йалңук оглы (огланы) мәңге калмас* – кеше (адәм баласы) мәңге яшәмәс.

***Йаминһу*** *г.* – Кара: *Ямин.*

***Йап*** *бор. төр.* – Астрономиядә зодиакаль *Укчы* йолдызлыгы, башкача – *Җәя, Кавәс.* Русчада – *Стрелец.*

***Йараббиі*** *г.* – Йа Раббым, йа Аллам.

***Йарак*** *тар.* – Тимер божралардан һәм тәңкәләрдән торган сугыш киеме. Идел буе болгарлары X–XIV гасырларда вак тәңкәле йараклар киеп сугышканнар, XII–XIII гасырларда эре тәңкәлеләре күбрәк кулланылган.

*Йарук* язылышы да очрый (русча «латы» мәгънәсендә).

Тагын кара: *Ярак. Җараклы.*

***Йараулы*** – Хезмәткә (эшкә) яраклы, сәламәт. Тау ягы Тархан сөйләшеннән.

***Йарпуз*** *бор. төр.* – Хәзерге терминологиядә – *мангуст (мангуста)* (елан тота торган җитез җәнлек). // *Йылан йарпуздан качар, канча барса, йарпуз утру келүр* – Елан мангустан качар, кая барса да, мангуст каршысына килер. «Диване лөгатет-төрк»тән (XI гасыр). *Утру* сүзе бүгенге телдә *отыры* формасында күзәтелә.

***Йас тоту*** – Вафат булган кеше өчен матәм тоту, кайгыру.

***Йасавыл*** *тар.* – Хәрби дәрәҗә. Рус теленә *есаул* (старшина) формасында кергән. Татар телендәге чыганакларда *йасаул* язылышы очрый.

Тагын кара: *Ясаул.*

***Йасриб*** *тар. – Мәдинә* шәһәренең әүвәлге исеме. Бүген *Ясриб* язылышы актив.

Кара: *Мәдинәи Мөнәүвәрә.*

***Йасуг*** *г.* – Гайсә пәйгамбәр. «Йасугүл-Мәсих» дип тә әйтелә (*мәсих* – мессия). Исламияттә – *Иса* (Гыйса), Библиядә – Иисус, борынгы еврейларда – *Иешуа.*

***Йасык*** *бор.төр.* – Кара: *Ясык.*

***Йаулы Тора*** – Себердә Исәт елгасы Тубылга кушылган җирдә урнашкан борынгы татар шәһәре. Атамадагы *йаулы* компоненты бу урында яу, сугыш булганга ишарә. Язылышта *Йала Тор* варианты очрый, ләкин ул рустагы атамадан бозылып кына барлыкка килгән. Себерне руслар яулап алганнан соң, *Йаулы Тора* рус шәһәре булып китә һәм «Ялуторовск» дип атала башлый.

Тагын кара: *Тора/тура.*

***Йаум*** *г.* – Көн, тәүлек. Коръәндә *йаум* сүзе теләсә кайсы озынлыктагы вакыт аралыгына карата (55:29 дагы кебек күз ачып йомган арага карата да, 70:4 тәге кебек илле мең елга карата да) кулланыла.

Күплек саны шәкеле – *әййам, әйям.* // *Былбыл мәүсиме әйям* – былбыл мизгеле көннәре, сандугач сайрар чаклар.

***Йаум (яум) әл-фөркан*** *г.* – Котылу көне. 624 елда Бәдер сугышында җиңү көне (мөселман гаскәренең).

***Йаум (яум) әт-тәрвия*** *г.* – Кара: *Тәрвия көне.*

***Йаумү-д-дин*** *г.* – Хисап көне (*йауме-л хисап*), Кыямәт көне. Русча – *судный день.*

***Йауме (яум) вагыйд*** *г.* – Кисәтү көне, янау көне. Русчадагы «День гнева» мәгънәсен бирә.

***Йахйа пәйгамбәр*** – Кара: *Яхъя пәйгамбәр.*

***Йахуд*** *ф.* – Яки. // *Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» исемле пьесасы башта «Мәкруһ яхуд Зөләйха» дип аталган.*

*Яхуд/яхут* язылышы да очрый.

***Йахшылар*** – Изгеләр. // *Түгел лаек яманлык йахшыларга.* Дәрдемәнд. *Кояш, үзенең яктысы кайда гына җитсә дә, андагы йахшыларга, йаманнарга бертигез йахшылык бирәдер.* Г. Тукай. *Астана тип йахшылар яткан урынга әйтәләр.* Д. Г. Тумашева. «Словарь диалектов сибирских татар» китабыннан. Бу сүз безнең якларда да шул ук мәгънәдә әйтелә. *Йахшылар кизләве.*

*Яхшылар* язылышы да очрый.

***Йаһу*** *г.* – Аллаһка сыгыну ымлыгы. «Йа» һәм «һуа» өлешләреннән тора, «и Алла», «йа Аллаһ, «әй Аллаһ», «йа Ходa», «йа Раббым» мәгънәсендә. (*Һу – Ул*, ягъни Алла.) *Яһу* язылышы да очрый. // *Йаһу, бу нинди кошмар? Бу нинди коточкыч бастырылу бу?* Ф. Әмирхан. *Яһу! Әлифба укыйк, без дә җир йөзендә башка кешеләр арасында торабыз, үзебезнең телебез бар, шуның белән сөйләшергә, укып язарга өйрәник!* Р. Фәхреддин. *Торам-торам да башым әйләнә башлый: яһу, Әстерхан татарлары донос ясауны галәмгә игълан итеп мактанырлык дәрәҗәгә килеп җиттеләрмени, дим.* Ф. Әмирхан. *Без кергәндә, өйнең залында мөритләр түгәрәкләнеп утырганнар. Түгәрәк уртасында зур чалма кигән Камчылы ишан утыра. Шау килеп, «яһу!.. яһу!.. яһу!.» дип кычкырып, тавышланып утыралар иде».* Г. Тукай турындагы истәлекләрдән Вафа Бәхтиярев хатирәләре.

***Йашрутийә*** – Тунис шәехе Гали әл-Йашрути (вафаты 1309/1891 елда) нигезләгән суфи борадәрлеге. Бу тарикать Сүриядә, Фәләстыйнда һәм Иорданиядә аеруча популяр була.

***Йә*** – Нинди дә булса эш-хәрәкәткә өндәүне, әйдәүне белдерә торган ымлык. *Йәгез, йәгезче* формаларында да очрый. // *«Йәгез, бер дога!»* – А. Гыйләҗевнең бер әсәре шулай атала. *Йәме?* – ярыймы? *Йә* – ярый.

***Йә саттарүн*** *г.* – Ят кешенең бусагасыннан атлап кергәнче, хатын-кызлар яшеренеп өлгерсеннәр өчен, ир-атлар әйтә торган сүз. «Бөркәнегез, качыгыз» мәгънәсендәге кисәтү.

***Йәалла*** *диал.* – «Бик, искиткеч» мәгънәсендә әйтелә. // *Ул әчте йәалла. Шуннан баеп киткән йәалла.* «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»ннән.

***Йәгирләр*** – Бу сүзне Г. Исхакый «гаскәриләр», «яугирләр» мәгънәсендә куллана. Х. Миңнегулов аны «егерьләр» дип аңлата. *Егерь* – немец теленнән рус теленә XVIII гасыр урталарында кергән сүз, төп мәгънәсе – «аучы, сунарчы», ләкин элек яллы «солдат» һәм «лакей» мәгънәләре дә булган. Европа армияләрендә *егерь* – җиңел пехота һәм атлы гаскәрнең бер төре. «Русско-турецкий словарь»да мин *егерь* сүзенең алынма булып кулланылуын күрмәдем. // *Финнар истикъляль тартышуларына Алманиядә үгрәнгән йәгирләрене оеткы итеп күңелле* [ирекле] *бер милли гаскәр мәйданга китерделәр.* Г. Исхакый.

***Йәгук*** *тар.* – Пәйгамбәр заманнарында Гарәбстанда аерым Йәмән кабиләләре табынган сәнам, пот. Сөнгатулла Бикбулатта: *Йәгук* – Һәмадан гарәпләре табынган пот. Коръәндә «Нух» сүрәсенең 23 нче аятендә *Вәд, Сүвагъ, Йәгус, Нәсер* исемле сәнамнәр белән янәшә телгә алына. Ул яңгыр өләшә торган булган. Бер риваятькә караганда, Йәгук исемле бер тәкъва кеше вафат булгач, Шайтан аның кабиләдәшләренә Йәгукның сурәтен ясарга киңәш биргән, имеш. Шуннан соң Йәгукың сурәте (статуясы) табыну өчен хезмәт итә башлаган. Дөрес, кайбер тәфсирчеләр Йәгукның сыны Хайван авылында торган һәм ат сурәтендә булган диләр.

Русча чыганакта *Яук* язылышында очрады, татарчада *Йәгух* язылышы да күренгәли.

***Йәгус*** *тар.* – Пәйгамбәр заманнарында Гарәбстанда аерым кабиләләр табынган сәнам, пот. Сөнгатулла Бикбулатта: *Йәгус* – Йәмәндә мәзхәҗ һәм кайбер башка кабиләләрнең поты. Пот куелган тау үзе дә «Мәзхәҗ» дип аталган. Бу потны үзләренеке итү өчен, төрле кабиләләр көрәшкәннәр. Коръәндә Йәгус «Нух» сүрәсенең 23 нче аятендә *Сүвагъ, Вәд, Йәгук, Нәсер* исемле сәнамнәр белән янәшә телгә алына. Тәфсирчеләр Йәгус арыслан кыяфәтле булган диләр, ләкин М. Б. Пиотровский бу фикер бернинди чыганак белән дә расланмый ди. Йәгус-алла яңгыр китерә торган булган, имеш. Сугыш вакытларында мәҗүсиләр Йәгус сынын үзләре белән ала торган булганнар.

Русча чыганакларда *Йагус* һәм *Йәгхус* язылышлары очрый.

***Йәгълимүл-гаиб*** *г.* – Яшерен серләрне белүче (Аллаһы турында, «Бакырган китабы»ннан, Казан, 2000).

***Йәд, ядь*** *г.* – **1.** Кул. // *Яшь төрек бәс мөстәбид ядь иснәмәз, пус әйләмәз.* Г. Тукай. *Йәд тула* – 1) озын кул; 2) тирән белем (күчерелмә мәгънә). **2.** Көч, куәт, кодрәт.

***Йәдәуи, йәдәви*** *г.* – Кулдан эшләнгән.

***Йәдү Аллаһи фәүка әйдиһи*** *г.* – Аллаһының кулы аларның кулыннан өстә.

***Йәздан (язьдан)*** *г.* – Барлыкка китерүче, Аллаһ. *Шириздан* исемен ясауда катнаша. Фарсы телендә – *Изад.*

***Йәзид ибн Могавия*** (вафаты 683 елда) – Әтисе Могавиянең вафатыннан соң хәлифәлекне васыять

буенча үз кулына алган. Күпчелек төбәкләр Йәзидкә бәйгать китергәннәр, ләкин Гали хәлифә тарафдарлары аңа каршы чыккан. Йәзиднең төп дошманы Имам Галинең улы, Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы әл-Хөсәен була. Хөсәен Йәзидкә тугры булырга ант итүдән баш тарта. Гали хәлифә тарафдарлары аны Куфәгә чакырып, җитәкчелекне үз кулына алырга тәкъдим иткәннәр. Ахырда ул моңа ризалык биргән һәм, башта Мәккәгә барып, аннан соң үзенең аз санлы гаскәре белән Куфәгә юнәлгән. Йәзид ибн Могавия аңа каршы Зияд ибн Әбиһинең улы Гобәйдулланы җибәргән. Гобәйдулла наиб Хөсәеннең тарафдарларын кулга ала. Аның гаскәре Кәрбәладә Хөсәеннең барысы 72 сугышчысын урап ала һәм бирелергә тәкъдим итә. Хөсәен моннан баш тарткач, Гобәйдулла гаскәре чын мәгънәсендә суеш оештыра. Дөрес, башта берсе дә Пәйгамбәрнең оныгына кылыч күтәрергә базмый, ләкин шулай да киндит кабиләсеннән Мәлик ибн ән-Нусайр дигән берәү Хөсәеннең башына кылыч белән суккач, барысы да аңа ябырыла... Сугыштан соң Хөсәен ибн Галинең башын Дәмәшкъка Йәзидкә җибәргәннәр. Соңыннан аны Кәрбәладә гәүдәсе белән бергә җирләгәннәр.

Бу үтереш ахыр чиктә Йәзиднең язмышын хәл итә дисәк ялгышмабыз. 682 елда Мәдинә шәһәре ачыктан-ачык Йәзидкә каршы баш күтәрә. Йәзид фетнәне бастырырга Гокбәнең улы Мөслим җитәкчелегендә күп санлы һәм яхшы коралланган гаскәр җибәрә. Хәррах бистәсе янындагы сугышта мәдинәлеләр арасыннан 270 әнсар үтерелә, һәм алар җиңеләләр. Аннан соң Мөслим көньякка – Мәдинәгә юл тота, чөнки мәккәлеләр дә Йәзидкә буйсынудан баш тарталар. Юлда Мөслим кинәт үлеп китә, ләкин Йәзид гаскәре Мәккәне барыбер чолгап ала. Ике арадагы атыш вакытында (сугышта, күрәсең, авыр ташлар ата торган *мәнҗәникъ* яки *зәнбәрәк*, ягъни катапульта кулланылгандыр) Кәгъбәдәге Караташ та зыян күрә – ул, ватылып, өч кисәккә аерыла. 683 елда 38 яшьләрдәге Йәзиднең көтмәгәндә вафат булуы һөҗүм итүчеләрне, сугышны туктатып, кире Дәмәшкъка кайтырга мәҗбүр итә.

***Йәзид** г.* – Риваятьләрдә – Шайтанга сатылган зат. Мәкерле кешеләргә карата әйтелә.

Кара: *Йәзидләр сектасы*.

***Йәзидләр сектасы*** – Көрдләр арасында таралган дини секта. Йәзидләр үзләренең дини күзаллауларында зороастризм, иудаизм, несторианлык, ислам һәм башка тәгълиматларның төрле элементларын кушып, бутап бетергәннәр. Алар карашынча, дөнья яратылганда, ике башлангыч – яхшы белән яман, яктылык белән караңгылык катнашкан. Алар яхшылык иясе булган Аллага да, «инкяр рухлы» Иблискә дә табыналар. Алар аны «Мәлик Тауза» дип атыйлар. Мәлик Тауза тәвә кошы сурәтендә була һәм йәзидләргә кушылган тормыш кагыйдәләренең ничек үтәлүен ныклап күзәтеп тора. Йәзидләр тәвә сурәтенә сәҗдә кылалар, дини нәмаешләр вакытында аның бакыр сынын күтәреп йөриләр, ләкин исемен (*шайтан* сүзен) атап әйтмиләр. Йәзидләр ахирәттәге тормышка ышаналар, сөннәткә утыртуны да, чукындыруны да кабул итәләр.

Йәзидләр әтәч итен ашамыйлар, чөнки ул тәвәгә охшаган, шулай ук балык һәм газәл итен дә капмыйлар. Алар фикеренчә, зәңгәр төс бәхетсезлек китерә. Йәзидләр чәчләрен озын йөртәләр, толымлап үрәләр, ә башларына очлы нәрсә кияләр. Алар үзләренең изге шәехләре дәфен кылынган каберләргә хаҗга баралар. Йәзидләр сектасын *Ади ибн Мөсафир* (вафаты 1161) нигезләгән. Аның төрбәсе тау үзәнлегендә урнашкан. Йәзидләрнең руханилары – Шәех Али нәселен дәвам итүчеләр.

Йәзидләрдә ураза өч көн генә дәвам итә. Ураза тоткан вакытта алар һәр көн иртән чыгып килгән кояшка таба карап гыйбадәт кылалар. Хатын-кызлары кайбер иркенлекләрдән файдалана. Кызлар, мәсәлән, үзләренә кияү сайлау хокукына ия, ә хатыннар, әгәр ирләре бер ел югалып торса, кабат кияүгә чыга ала.

Мөселман, нәсрани һәм йәһүдиләр кебек китап әһелләре булмаганнары өчен, аларны габбаси хәлифәләр дә, төрекләр дә эзәрлекләгән. Йәзидләрнең гомуми саны күп түгел, 20 мең чамасы гына. Шуның яртысы Гыйракта, калганнары Сүриядә һәм Иранда яши.

***Йәйаг** иск.* – Җәяү(ле). Элек «йәйаглар» дип хаҗиларга әйткәннәр. *Пехота* сүзенә татарча тәңгәл эзләгәндә, бу сүзнең кирәге чыгуы мөмкин.

***Йәлавыч** бор.* – Апостол, хәвари(йун), хәбәрче. *Йәлавыч* сүзе Сәгыйть Хәлфиннең кулъязма сүзлегенә теркәлгән, Мәхмүд Кашгарыйда да очрый. «Древнетюркский словарь»да *йалавач* термины «илче», «хәбәрче», «пәйгамбәр» дип аңлатыла. «Рисаләи Газизә»дә *ялавач* язылышына тап булабыз. Бу китапта, мәсәлән, Зәкәрия һәм Шәмгун кебек пәйгамбәрләр йәлавычлар исәбенә кертелә, ә Идрис, Шис һәм Муса пәйгамбәрләр – кәбирләр, ягъни зурлар, алары «сәүчи» дип аталган. // *Ул вакытта Мисыр газиз Кыйтфир иде, Ялавычлар бөти белән аңа килде.* «Йосыф вә Зөләйха»дан. Монда *ялавыч* сүзе «яучы» мәгънәсендә килә.

Тагын кара: *Юлавыч*.

***Йәләмләм** тар.* – Мөхәммәд пәйгамбәр Йәмән әһелләренә ихрамга керү өчен билгеләгән урын – биш микатның берсе. Йәләмләм – Мәккәдән ерак түгел бер тау.

***Йәм*** I – Һинд-Иран мифологиясендә мәңге суын эчкән каһарман.

***Йәм*** II – Нух пәйгамбәрнең кече улы. Туфан вакытында Йәм атасы белән бергә көймәгә утырырга риза булмый, су басудан тау башына менеп котылырга исәп тота. Ләкин Йәм зур дулкында һәлак булган.

***Йәмәкләр*** *тар.* – Кимәк этносының нигезен тәшкил иткән төрки кабиләләр. X гасырда алар Көнбатыш төрки каһанлыгына кергәннәр һәм Алтай, Иртеш тирәләрендә күчмә тормыш алып барганнар.

Кайбер галимнәр Казан татарларының нигезен йәмәкләр тәшкил итә дип саныйлар. Татарстанның Минзәлә районында Җәмәк авылы (русча – *Ямаково*) бар, Кама Тамагы районында тагы бер Җәмәк авылы булган, ләкин ул беткән. Йәмәк исеме белән бер елга да теркәлгән (Фирдәвес Гарипова). Татар сөйләшләрендә *йәмәк мае* – горчица (русча).

***Йәмән*** – Гарәбстан ярымутравының көньяк-көнбатыш өлешендәге төбәк. VII гасырда җирләре аша зур сәүдә юллары үткәнгә, Йәмән иле бай булган һәм аны «Бәхетле Гарәбстан» дип атап йөрткәннәр. Хатын-кыз исеме *Мәймүнә* – «Йәмән кызы» яки «бәхетле кыз» мәгънәсенә ия (ә Бинйәмин/Ибнеямин – бәхетле угыл).

Мәккәдә Кәгъбәнең көньяктагы почмагы «әр-рөкен әл-йәмәни» дип атала (Йәмән почмагы, – көнчыгышка карап басканда, уң кул яктагы почмак; ул Шамга, ягъни сул якка – хәзерге Сүриягә каршы якта).

Рус телендә – *Йемен.*

***Йәмән республикасы*** – Гарәбстан ярымутравында урнашкан ил. 1990 елда Йәмән Халык республикасы һәм Йәмән Халык Демократик республикасы бергә кушылганнан соң оешты. Халкы 10,6 млн чамасы, күпчелеге гарәпләр (Шәфигый юнәлешендәге сөнниләр һәм шигый зәйдитләр һ. б.). Илнең башкаласы – Аден шәһәре (борынгы *Гаден*, Библиядә – *Эдем*). Йәмән республикасын президент җитәкли. Акча берәмлекләре – Йәмән риалы һәм Йәмән динары.

***Йәмин/йәмийн*** *г.* – Кара: *Ямин.*

***Йәмәхрәм*** *г.* – Шәригать буенча беркайчан да никахлашырга рөхсәт ителмәгән кан кардәшләр.

Тагын кара: *Мәхрәм. Намәхрәм.*

***Йәрәкан гыйлләте*** *г.* – Сары авыруы, сары зәхмәте.

***Йәрәкә*** *диал.* – Минзәлә яклары сөйләшендә – зур көймә, кораб.

***Йәрен*** *диал.* – Ярен. *Йәренге* – киләсе ел, буласы ел. Бу сүз бик күп сөйләшләрдә күзәтелгәнгә, аның «статусын» күтәреп, гомум әдәби сүз итәргә вакыт. Халык телендә ахирәтне *йарын*, ягъни «иртәгесе көн», «киләчәк көн» дип атау күзәтелә. // *Улым әрмийәдән йәрендә кайтасы.* Сөйләм теленнән. *Ярен әйтмә, борын әйт* – «иртәгәгә калдырма, алдан ук әйтеп куй» мәгънәсендә.

***Йәсин сүрәсе*** – Мәккә чорының урталарына нисбәт ителә, 83 аятьтән тора. «Йә», «син» хәрефләре белән ачыла, исеме дә шуннан. Коръәннең русчага тәрҗемәләрендә сүрә «Йа Син» (Мәүлана Мөхәммәд Али, И. Ю. Крачковский, «Аль-Мунтахаб» тәфсире) һәм «Йа-Син» дип алынган (В. Порохова). Б. Я. Шидфар тәрҗемәсендә – «Йа Син» (*«Я, Син»*). «Коръән-Кәрим» китабында сүрәнең исеме транскрипциялəп бирелә: «Йәә сиин». Рабит Батулла тәрҗемәсендә – «Йасин сүрәсе». Кайчагында аның исеме «Йа инсан!» – «Йә кеше!» дигән гыйбарә кыскарып барлыкка килгән дигән фараз очрый. Мәүлана Мөхәммәд Али да аны шул мәгънәдә аңлата («Священный Коран» китабы). Кайбер авторлар монда Аллаһ, гомумән, кешегә генә түгел, бәлки Үзенең илчесе Мөхәммәдкә мөрәҗәгать итә дип уйлыйлар. «Йәсин» сүрәсе физик авыртуларны җиңеләйтә дип санала, шуңа күрә аны үлем түшәгендә ятучы янында, ураза тоткан вакытта, шулай ук мәет җирләгәндә укыйлар, бу сүрә язылган кәгазьне тылсымлы бөти итеп тагып йөриләр. Хәдискә караганда, Мөхәммәд пәйгамбәр «Йәсин» сүрәсен «Коръәннең кальбе (йөрәге)» дип атаган. // *Йәсин чыгу (уку)* – үлем түшәгендә яткан кешенең гөнаһларын кичерүне сорап, «Йәсин» сүрәсен уку. «Бу мөбарәк сүрәне берьюлы җитмеш мәртәбә укучы кеше һәр морадына ирешер». Хәзерге татарча чыганакларда *ясин* һәм *йасин* язылышлары да очрый. *Йасин хастаханәсе.*

***Йәсир*** – Мөхәммәд пәйгамбәрнең замандашы, ислам динен кабул иткән христиан колларыннан. Аның улы *Гаммар* Пәйгамбәрнең иң якын унике сәхабәсеннән булган. Йәсир, аның хатыны Сүммия һәм угыллары Гаммар корәешләр тарафыннан җәзалап үтерелгәннәр.

*Ясир* язылышы да бар.

***Йәсту намазы*** – Кара: *Ясту намазы.*

***Йәүмүл әрбәгаи*** *г.* – Чә(һа)ршәмбе (*йәүм* – йаум, көн; *әрбәгаи* – дүртенче; *чәһар* – фарсыча дүртенче).

***Йәүмүл әхәд*** *г.* – Якшәмбе көне (*әхәд* – беренче).

***Йәүмүл җомгати*** *г.* – Җомга көне.

***Йәүмүл иснәйни*** *г.* – Дүшәмбе көне (шимбәдән соң атнаның икенче көне).

***Йәүмүл кыямәт, йәүмүл-вәгыйд(ь), йәүмүл-хисаб*** – Кыямәт көне, кисәтү көне, Ахырзаманда Аллаһы хозурында олуг хисап (хөкем) көне. Ләкин бүгенге сәяси хәрәкәттә активлашкан русча *день гнева* сүзен «кисәтү көне (йәүмүл вәгыйдь)» дип аеру кулай тоела.

***Йәүмүс сәбти*** *г.* – Шимбә көне (*сәбти – суббота* сүзе белән бер нигездән).

***Йәүмүл сүләсә-и*** *г.* – Си(һ)шәмбе көне (атнаның өченче көне).

***Йәүмүл хәмиси*** *г.* – Пәнҗешәмбе көне (атнаның бишенче көне).

***Йәүшән*** *бор.* – Кираса (күкрәкне һәм арканы саклый торган металл кием, көбә күлмәк, шаң).

***Йәфсаль*** яки ***Йәфтали*** – Библиядә – *Неффалин.* Йосыфның атадаш туганнарыннан берсе.

***Йәһмүдә*** – Җирне күтәреп торучы *Ләйвәсан* (яки *Ләйвсан*) үгезен күтәреп тора торган балык (Чаг.: *Нун* балыгы һәм *Яһүдә* үгезе).

***Йәһүд*** – Кара: *Яһүд.*